ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТЮГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТӨГИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**КАРАР**

12.05.2026 № 6

Төги ав.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Башкарма комитетының 2012 елның 07 мартындагы 3 номерлы карарын «Төги авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» үз көчен югалтуын тану хакында**

«Хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ Федераль законына, Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 07 мартындагы 3 номерлы «Муниципаль берәмлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны уземдә калдырам.
4. Әлеге карар рәсми бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Башкарма комитет җитәкчесе Т.В. Попова